


Яз башы каникуллары тиз генә vтеп тә китте инде. Мордовия мәктәпләрендә укучылар гына тvгел, укытучылар да вакытларын фәйда белән vткәрделәр.
Үткән атнада Ләмберә балалар-яшvсмерләр спорт мәктәбе белән Ләмберәнен беренче мәктәпләре базасында ел саен vткәрелә торган район мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре профсоюз Спартакиадасында 22 профсоюз оешмасыннан 16 командада 81 катнашучы булган. Ярышлар волейбол, шашка, шахмат, теннисны популярлаштыру, педагогларнын ялын оештыру һәм спортны пропагандалау максатында vткәрелгән. Спартакиада жинvчеләрне бvләкләv тантанасы белән тәмамланган. Ин яхшы командалар һәм спортчылар грамоталар, сертификатлар белән бvләкләнгәннәр.
Спартакиада призерлары тvбәндә. Шашка буенча - «Солнышко» Ләмберә балалар бакчасы, №3 Ләмберә балалар бакчасы белән Ләмберә балалар-яшvсмерләр спорт мәктәбе (ДЮСШ), Кривозерье, Первомайский, Пензятка мәктәпләре командалары. Мәсәлән, Пензятка урта мәктәбе укытучылары һәрбер тор ярышта vзләрен сынатмаганнар - жинvчеләр. Алар - Регина Фаиль кызы Заликова остәл теннисы буенча - оченче, ә Равза Мукаддяс кызы Юмаева шахмат буенча беренче урын яулаганнар.
Волейбол буенча беренче урын - Атемар урта мәктәбе, икенче  – Пензятка урта мәктәбе, оченче - Ләмберәнен беренче мәктәбе командалары.
Барлык катнашучылар да кvнел кvтәренкелеге һәм унай хис-кичерешләр алган.
Укучыларнын да каникуллары фәйдалы vткән. Мәсәлән, һонәри юнәлеш бирv кысаларында, Рузаевка районы Трускляй авы-лындагы «Стрелецк» хужалыгы зоотехнигы Руслан Раиль улы Манеев 10 сыйныф укучылары очен мавыктыргыч һәм кызыклы экскурсия vткәргән. Ул укучыларны терлекчелек комплексында vз-vзенне тоту кагыйдәләре белән таныштыра, сыерларнын кайда асралуы, нәрсә белән туклануы, бозаулар, аларны карау шартлары һәм һәр бозаунын кондәлек рационы турында сойләгән. Укучылар агроном, зоотехник, ветеринария табибы, лаборант кебек һонәрләр белән кvреп танышканнар.